ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

28.09.2020　　　　　　　　　　№ 137

с. Введенская Слобода

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 нче елның 17 нче октябренә Югары Ослан муниципаль районы Елизаветино авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Елизаветино авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы:

- Елизаветино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК»

3. Елизаветино авылы, Солнечная урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт яны территориясендә гражданнар җыены үткәрергә.

4. Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы　　　　　　Д. В. Морозов